КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 830

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 июнь, 555 нче карары белән расланган Әйләнештәге акчаны тулыландыру максатларында 2022 елда сәнәгать үсеше фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү максатларында фондның эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә (докапитализацияләүгә) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» 1990 елның 2 декабрендәге 395-1 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредит оешмалары белән төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен компенсацияләүгә грантлар рәвешендә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Әйләнештәге акчаны тулыландыру максатларында 2022 елда сәнәгать үсеше фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү максатларында фондның эшчәнлеген финанс белән тәэмин

итүгә (докапитализацияләүгә) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» 1990 елның 2 декабрендәге 395-1 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредит оешмалары белән төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен компенсацияләүгә грантлар рәвешендә субсидияләр бирү тәртибен раслау хакында" 2022 ел, 14 июнь, 555 нче карары белән расланган Әйләнештәге акчаны тулыландыру максатларында 2022 елда сәнәгать үсеше фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү максатларында фондның эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә (докапитализацияләүгә) сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» 1990 елның 2 декабрендәге 395-1 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредит оешмалары белән төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен компенсацияләүгә грантлар рәвешендә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның өченче абзацында «20.53, 20.59, 24.46 төркемнәр, 20.14.1 төркемчәләр» сүзләрен «20.53, 24.46 төркемнәр, 20.14.1, 20.59.2, 20.59.6 төркемчәләр» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта:

«д» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) әлеге Тәртип кысаларында сәнәгать субъекты алган финанс ярдәменең җыелма күләме 50 млн. сумнан артмый.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Грант рәвешендә финанс ярдәме Фонд тарафыннан грант алуга гариза бирү аеның 1 көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган сәнәгать субъектларына бирелә:

а) сәнәгать субъекты тарафыннан Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагына керә торган икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;

б) сәнәгать субъектын юридик зат, шәхси эшкуар буларак теркәлү дәвамлылыгы финанс ярдәме күрсәтү өчен гариза бирелгән көнгә кадәр кимендә 24 календарь ай тәшкил итә;

в) Татарстан Республикасы территориясендә салым түләүче буларак сәнәгать субъектын теркәү;

г) башка норматив хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 3.1 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән кредит линиясен ачу турында кредит шартнамәсе һәм (яисә) кредит шартнамәсенә өстәмә килешү буенча сәнәгать субъекты тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан финанс ярдәме алмау, шулай ук сәнәгать субъектының кредит оешмасы белән төзелгән кредит шартнамәсе буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен компенсацияләүгә башка дәүләт үсеш институтлары тарафыннан бирелә торган акчалар алмау;

д) сәнәгать субъектының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар,

штрафлар һәм процентлар түләү буенча бурычы 50 мең сумнан артыграк күләмдә булмау;

е) сәнәгать субъектының чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

ж) сәнәгать субъектына - юридик затка карата ликвидация, банкротлык, үзгәртеп кору процедураларының үткәрелмәве (башка юридик зат сәнәгатенең әлеге субъектына кушылу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш), шулай ук административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә сәнәгать субъекты эшчәнлеген туктатып тору, сәнәгать субъекты шәхси эшмәкәр булган очракта, ул шәхси эшмәмәр буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

з) сәнәгать субъекты экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

и) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 31 декабренә кадәр үз көченә кергән көннән алып 2022 елның 31 декабренә кадәр чорда грант биргәндә Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлар тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмау;

3.3 пунктының «г» пунктчасында «каралмаган» сүзләрен «каралган» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин